

Татар милләте гражданнары яшәгән һәр торак пунктта диярлек мәчет тозелгән. Моселман гореф-гадәтләре буенча, дин әһеле коненә биш тапкыр мәчеткә йорергә тиеш. Әйтик, кvрше авылга йорv авыр, шуна да vзләрендә мәчетне сафка бастырылган. Ельники районы Чурино авылындагы мәчет 1993 елда янадан тозелгән.      Ботен донья белән торгызылган. Изге эшкә кем кvпме иганә итә алганына акча биргән. Санкт-Петербургта яшәvче байлар, Мәскәvдә яшәvчеләр саллы суммаларны корбан иткән. Ул вакытта монда дини елаларны имам-хатыйб Шәриф Хәсән улы Кутуев башкарып килгән. Егерме сигез елын Аллага хезмәт итvгә багышлаган дип әйтергә кирәк. Анын турыдан-туры житәкчелеге һәм катнашында мәчет тозелә. Бvген Шәриф Хәсән улы, сәламәтлек торышы буенча, дини эшләрдән читләште.

Агымдагы елнын 2 маенда, Чурино авылы карары белән, Ринат Руфәт улы Кутуев мулла итеп сайланган. Чагыштырмача яшь кеше. Ни очен ана хормәтле хәзрәт булу хормәте кvрсәтелә? Без кайбер авыл кешеләреннән сораштык һәм алар барысы да Ринатнын ислам дине мәсьәләләрендә «белемле» булуына тошендек. Ул Коръәнне дә, бу вазифага лаеклы кеше буларак та белә. Торак пунктнын vз мулласы булырга тиеш. Бу модага хормәт тvгел, ә кирәк. Әйтик, гаиләдә бәхетсезлек очрагы булган икән, мулла беренче сәгатьләрдә vк мәрхvм буенча дога укырга тиеш. Аннары, кеше тәне кvмәргә әзерләнгәч, тагын бер тапкыр дога укыла. Тагын бер мисал, яшьләр гаилә корырга булсалар, ЗАГС- тан тыш, мен еллар элек булган гореф-гадәт тә  бар. Никах вакытында мулла билгеле бер йола vткәрергә һәм тиешле дога укырга тиеш. Шул вакытта гына алар Аллаһы Тәгаләнен ире һәм хатыны дип танылалар.

Дингә карата без кайбер авыл кешеләре белән сойләштек. Шәриф Ариф улы Тангалычев:

- Мин vземне чын моселман дип саныйм. Мин барлык язмаларны һәм гореф-гадәтләрне vтәргә тырышам. Башкача ярамый. Әти-әниләребез шулай ойрәтте, без моны балаларыбызга да ойрәтәбез.

Равиль Ислям улы Кутуев:

- Минем әти-әнием мина һәрвакыт безнен гореф-гадәтләребезне vтәргә куштылар. Һәр моселман кебек vк, момкин булганча мәчеткә барам, ата-бабаларымнын каберлекләренә йорим. Мин ата-бабаларым белән горурланам.

Хәзерге мулла һәркемне канә-гатьләндерә. Без Ринат Руфәт улы белән очрашып, аны сайлап алу турында сойләштек. Ринат Руфәт улы:

- Әгәр православие динен тотучылар, рухани булганчы, семинарияне тәмамларга тиеш

икән, бу яктан бездә жинелрәк. Ләкин, бу жаваплылык азрак дигән cvз тvгел. Мина дин олкәсендәге кайбер сорауларда авылдашлар, шулай ук якташым Марат Шехмаметьев ярдәм итте. Бvген ул Первомайск шәһәренен бер мәчетендә мулла. Гаиләм шулай ук барлык ислам кануннарын тота. Улларым Ильнур, Ильнар һәм хатыным Равилә – барысы да ураза тоталар, дога кылалар. Без туганнарыбыз һәм якыннарыбызнын исән-сау булуларын, Аллаһы Тәгаләдән доньяларыбызда тынычлык бул сын һәм хезмәтләребез очен рәхмәт белдерvе турында сорап дога кылабыз.
Безне бер катлаулы сорау кызыксындырды һәм без аны бирдек - православие динен тотучыларнын билгеле бер урында торле изгеләрнен иконалары эленеп тора, ә бу жәһәттән сез ничек уйлыйсыз?
- Һәр моселман гаиләсендә Коръән сvрәләре бар. Алар да иконалар ролен башкаралар. Шунысын да билгеләп vтәргә кирәк, Чурино авылында vзенчәлекле халык; аралашырга, бераз мактанырга да яраталар. Әгәр дә берәр нәрсә дорес булмаса, алар турыдан-туры кvзгә атып әйтәләр, кеше артында пышылдамаслар. Кайбер кирпеч йортлар кvзгә ташлангач, урамнар буйлап узарга булдык. Чурино авылы бай, халкы кунакчыл. Берничә минут эчендә мул остәл дә куярга момкиннәр.
Бvгенге тормыш чынбарлыгы бу ерак почмакка да эз калдырды. Кичләрен балаларнын янгыравыклы тавышларын ишетеп булмый. Авыл, туры һәм кvчмә мәгънәдә, картайды. Пенсионерларны гына урамнарда кvрергә була. Барча социаль унайлыклар авылда бар, хәтта сәvдә ноктасы да; кирәк-яракларнын барысы да бар. Башка авыллардагы кебек, шырпы яки тоз артыннан район vзәгенә барырга кирәкми. Халык vзләре әйткәнчә, «Аллага шокер, бар да әйбәт. Тынычлык булсын иде дә, сәламәтлек бетмәсен иде».

**«Ельниковская трибуна» газетасыннан**